РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА**
**Балтачевского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Школьная, 1, с. Балтачево,
Камско-Устьинский район, 422829
тел./факс: (884377) 366-40
ОГРН 1061672018044
ИНН/КПП 1622004637/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Балтач**
**авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

Мэктэп урамы, 1, Балтач авылы,
Кама Тамагы районы, 422829,
тел./факс: (884377) 366-40
ОГРН 1061672018044
ИНН/КПП 1622004637/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**19 май 2023 ел** **№ 9**

**Хуҗасыз хайваннарны кайтару тыелган урыннарны билгеләү һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында Карар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеге турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы ассоциациясенең» 2023 елнын 26 апрелендэге №409 хаты нигезендэ, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының "Балтач авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган түбәндәге урыннарны билгеләргә:

ФАП территориясе;
Парк территориясе;
Балалар мэйданчыклары территориясе;
Мэдэният йортлары территориялэре;
Ял зоналары территориялэре;
Мэчет территориясе;
ТКО территориясе.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Мохэммэдуллин Динар Имаметдин улын хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итүче вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Балтач авылы, Мэктэп ур., 1;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Балтач авылы, Мэктэп ур., 2;

Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан коненнэн үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе ____________________Д.И.Мохэммэдуллин